

# Чын кеше

- һәрвакыт табигый
- яхшы сыйфатларга ия
- һәркемгә үрнәк

- 

  **Чын кеше:**
- -        юмарт;
- -        яхшы күңелле;
- -        ихлас эчкерсез;
- -        саф йөрекле;
- -        акыл белән эш итә;
- -        игелекле, изгелекле;
- -        миһербанлы;
- -        намуслы.



“Бала чактан  алынган тәрбияне соңыннан дөнья халкы да
үзгәртә алмас.”

Ризаэтдин  Фәхретдин



- **Үз-үзеңне тәрбияләү өчен нәрсәләр эшләргә кирәк?**
- **1. Үз-үзеңне тәрбияләүнең кирәклеген тирәнтен аңларга, үз көчеңә ышанырга; акыллы кеше буларак, ныклы омтылыш белән яшәргә.**
- **2. Үзеңдә нинди сыйфатлар үстерүдән чыгып, үз-үзеңне тәрбияләүнең максатын төгәл билгеләргә.**
- **3. Көндәлек режим һәм үз өстендә эшләүнең графигын төзеп, күренеп торган урынга беркетергә.**
- **4. Үз-үзеңне тәрбияләүнең нигезе буларак, ихтыяр көченә аеруча игътибар итәргә.**
- **5. Үз-үзеңне таныл бел. Үз сәләтеңне, интересларыңны ачыклап, кирәкле вакытта физик һәм рухи көчләреңнең "резерв"ларын таба бел.**
- **6. Үз-үзеңне тәрбияләүнең иң яхшы үрнәкләрен бөек кешеләрнең тормышыннан һәм язучыларның әсәрләреннән эзлә, дәфтәреңә язып бар.**
- **7. Коллективта һәм җәмәгать эшендә үз-үзеңне тәрбияләү өчен таяныч тап, аеруча тәнкыйтьтә һәм үз-үзеңне тәрбияләүдә. Синең хакта иптәшләреӊ нәрсә уйлаганын бел.**
- **8. Яхшы тәҗрибәгә колак сал, үзең булып кал, үз-үзеңне мактаудан саклан.**
- **9. Тәрбия эшенең асылын физик күнегүләр, түземлелек, кыюлык бар нәрсәне дә азагына кадәр җиткерә белү хәл итә.**
- **10. Тормышта, хезмәттә, укуда түбәндәге принципларны искә ал: һәр нәрсәне үзең эшлә; ни дә булса килеп чыкса, үз гаебеңне таба бел, авырлыклардан курыкма, аларны үзең эзләп тап; үз эшеңә үзең бәя бирә бел, эгоист булма, кешеләрне аңлый белү сәләтенә өйрән. Үз-үзеңне бәләкәй генә җиңү дә кешене көчле ясый. Башта уйла, аннары эшлә.**

Акыл акыл



